ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯМАЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

423753, Татар Ямалы авылы,
Ленин ур.,6 нчы йорт.
Тел.:(85552)3-44-58; .
E-mail: tyamal-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
ТАТАРСКО-ЯМАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423753, село Татарские Ямалы,
ул.Ленина,дом 6.
Тел.:(85552)3-44-58;
E-mail: tyamal-akt@yandex.ru

КАРАР — ПОСТАНОВЛЕНИЕ

28.02.2025ел — №6

**Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Татар Ямалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» 16.03.2020 ел, № 6 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2022 № 1081 карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Татар Ямалы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Башкарма комитетының 16.03.2020 ел, № 6 карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы " Татар Ямалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлегенең 3.6 пунктында:
- А) икенче абзацта", дәүләт (муниципаль) программаларының структур элементларына" сүзләрен төшереп калдырырга;
б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр санының һәм ташламалар куллану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яисә түләүчеләрнең гомуми санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана торган бирелгән ташламаларны түләүчеләрнең ихтыяҗы.";
в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларның түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән ташлама кирәк дип таныла торган чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин.".

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 3.9_1 пункт өстәргә:
3.9_1. Кирәк булганда салым чыгымы кураторы тарафыннан Россия Федерациясе субъекты (муниципаль берәмлек)салым чыгымының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүнең өстәмә критерийлары билгеләнергә мөмкин

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 3.10_1 пункты өстәргә:
3.10_1. Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) са-

лым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) техник салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рөхсәт ителә.

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтындагы "Авыл җирлекләре" бүлегендә түбәндәге адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Л.Ф.Лутфуллина